| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан**<br>**Старо-Имянское сельское поселение Сармановского муниципального района** | **Татарстан Республикасы**<br>**Сарман муниципаль районының Иске Имән авыл җирлеге** |

| | |
|---|---|
| **КАРАР**<br>**16.12.2025 ел** | **КАРАР**<br>**№12** |

Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрелендәге «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге сайланулы вазыйфаи затына хезмәт өчен түләү нигезләмәсен раслау турында» 81 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, Рәис урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 елның 25 ноябрендәге 994 карары, Сарман муниципаль районының «Иске Имән авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән, Иске Имән авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Советының 2028 елның 27 апрелендәге «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге сайланулы вазыйфаи затына хезмәт өчен түләү нигезләмәсен раслау турында» 81 номерлы карарына (Сарман муниципаль районы Иске Имән авыл җирлеге Советының 2018 елның 21 июнендәге 86 номерлы, 2018 елның 8 ноябрендәге 101 номерлы, 2020 елның 21 сентябрендәге 9 номерлы, 2020 елның 14 декабендәге 17 номерлы, 2024 елның 21 июнендәге 105 номерлы, 2025 елның 30 апрелендәге 129 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 нче кушымтаның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларын, депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын, контроль-хисап органнары рәисләрен айлык акчалата бүләкләү күләмнәре:

| Вазыйфа исеме | Айлык акчалата бүләкләү күләме, сум | | |
|---|---|---|---|
| | 10 группа* | 11группа* | 12 группа* |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 27 601 | 25 401 | 23 201 |

үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, сайланулы җирле үзидарә вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары,«үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 182 номерлы карары белән расланган.

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.
3.Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» халыкка җиткерергә (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Иске Имән авыл җирлеге Советы рәисе: Р.Ә.Исламова